Татарстан Республикасы исеменнән

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КОНСТИТУЦИЯ СУДЫ
**КАРАРЫ**

**гражданин И.А. Макаров шикаятенә бәйле рәвештә «"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасының, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацлары белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктларының аерым нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эш буенча**

Казан шәһәре 2020 елның 14 феврале

Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясына (дүртенче өлеш), «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче һәм тугызынчы өлешләренә, 39 статьясындагы беренче өлешенә һәм икенче өлешенең 1 пунктына, 68, 83, 100, 101 һәм 103 статьяларына таянып,

ачык суд утырышында «"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасының, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацлары белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктларының аерым нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү турындагы эшне карады.

Эшне карауга гражданин И.А. Макаров шикаяте сәбәп булды. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган норматив нигезләмәләрнең Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә килеп туган билгесезлек эшне карауга нигез булды.

Докладчы судья А.Р. Шакараев мәгълүматын, дәгъва белдерелә торган норматив хокукый актларны чыгарган органнар вәкилләре — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы урынбасары — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең социаль законнар бүлеге мөдире Д.И. Мәхмүтов, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты аппараты Хокук идарәсенең торак законнары мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары — Э.Я. Тимерханова аңлатмаларын, суд утырышына чакырылган: Татарстан Республикасы Президенты вәкиле — Татарстан Республикасы Президенты Дәүләт-хокук идарәсенең ярлыкау мәсьәләләре буенча секторы мөдире Д.А. Рослов, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкиле — Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты Хокук идарәсенең социаль законнар бүлеге баш киңәшчесе А.А. Адыева, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты — Татарстан Республикасы Хөкүмәте вәкиле — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башлыгы А.Б. Гревцов, Татарстан Республикасы Югары суды Рәисе вәкиле — Татарстан

Республикасы Югары суды судьясы Э.С. Каминский, Татарстан Республикасы Арбитраж суды Рәисе вәкиле — Татарстан Республикасы Арбитраж судының суд практикасын анализлау һәм гомумиләштерү бүлеге баш белгече Э.И. Гафиятуллина, Татарстан Республикасы Прокуроры вәкиле — Татарстан Республикасы прокуратурасы Федераль законнар үтәлешенә күзәтчелек итү идарәсенең норматив хокукый актларның законлылыгына күзәтчелек итү бүлеге башлыгы А.Р. Вәлиәхмәтов, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилдән — Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппаратының гражданнар хокукларын торгызу мәсьәләләре бүлеге башлыгы урынбасары Р.И. Сәйфетдинова чыгышларын тыңлап, тапшырылган документларны һәм башка материалларны өйрәнгәннән соң, Татарстан Республикасы Конституция суды

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданин И.А. Макаров «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасының, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацлары белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктларының аерым нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 5 пунктының «а» пунктчасы белән «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында»

2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясының 1 пунктында «торак урыннарга мохтаҗ дип» сүзләре «билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип» сүзләренә алмаштырылган.

Мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 пунктының нигезләмәләре (алга таба шулай ук — Административ регламент), муниципаль хезмәт, шулай ук муниципаль хезмәтләрне күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен законнар яки башка норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлегенә әлеге регламентка 1 нче кушымта нигезендә документларны (төп нөсхәләрне) кертәләр.

Административ регламентның 2.8 пунктының дәгъва белдерелә торган нигезләмәләре муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез итеп тәкъдим ителгән документларның каралучы регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәвен карый.

Гражданин И.А. Макаров шикаять белдерә торган Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пункты нигезләмәләре буенча, йорт кенәгәсеннән өземтә бирү өчен, шул исәптән йорт кенәгәсе һәм шәхси торак йортка хокуклар турында документ (хокукны дәүләт теркәве турында таныклык яки шәхси торак йортның техник (кадастр) паспорты, яки Ростехинвентаризациянең — Федераль техник инвентаризацияләү бюросының Татарстан Республикасы филиалыннан хокук ияләре турында белешмә) кирәк.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документларның күчермәләреннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүче — Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 29 ноябрендәге 987н номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарның бер фатирда бергә яшәүләре мөмкин булмаган хроник авыруларның авыр формалары исемлегенә кергән авыр хроник авырудан интегүче инвалид. Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ буларак исәпкә кую максатында гражданин И.А. Макаров, гаризага «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән документлар исемлеге һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 7 июнендәге 432 номерлы карары белән расланган Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннары наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 2.2 пункты нигезендә каралган документларны кушып, Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясенә (алга таба шулай ук — Администрация) гариза белән мөрәҗәгать иткән. Әмма Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы күрсәтмәсе нигезендә мөрәҗәгать итүчегә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗ буларак исәпкә куюдан баш тартылган, чөнки әлеге күрсәтмәдән өземтәдә күрсәтелгәнчә, гражданин И.А. Макаров аз керемле дип танылырга мөмкин һәм аның тарафыннан йорт кенәгәсеннән өземтә, йортка техник паспорт (күчермә) бирелмәгән.

Мөрәҗәгать итүче, «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы

Татарстан Республикасы Законы кабул ителгәнчегә кадәр (алга таба шулай ук — 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы) торак урыны алу өчен торак субсидиясен (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирү юлы белән торак шартларын яхшырту хокукына Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче барлык инвалидлар, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче инвалид балалары булган, торак урыннарына мохтаҗлар дип танылган һәм 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан гаиләләр ия булган иде дип күрсәтә. Аның фикеренчә, 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының дәгъва белдерелә торган нигезләмәләре белән кертелгән үзгәрешләр, тигезлек һәм гаделлек, социаль дәүләтнең конституциячел принципларына карамастан, инвалидларның аеруча мохтаҗ булган өлешен — аз керемлеләрне, аларга бирелгән торак субсидиясен алу хокукыннан, социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар буларак исәпкә куюның законнар белән билгеләнгән шартларына туры килмәү сәбәпле, мәхрүм иткәннәр.

Гражданин И.А. Макаровка тиешле исәпкә куюдан шул исәптән йорт кенәгәсеннән өземтә бирелмәү нигезендә баш тартылганлыктан, аны бирү турындагы гариза белән ул Администрациягә мөрәҗәгать иткән. Ләкин Администрация, дәгъва белдерелә торган Административ регламент нигезендә өземтә алу өчен шул исәптән йорт кенәгәсе һәм шәхси торак йортка хокуклар турында документ (хокукны дәүләт теркәве турында таныклык яки шәхси торак йортның техник (кадастр) паспорты, яки Ростехинвентаризациянең — Федераль техник инвентаризацияләү бюросының Татарстан Республикасы филиалыннан хокук ияләре турында белешмә) тапшырырга кирәк дип билгеләп, аңа йорт кенәгәсеннән өземтә бирүдән баш тарткан.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, «Социаль файдаланудагы торак

фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясындагы 3 өлеше һәм Тәртипнең 2.4 пункты нигезендә, йорт кенәгәсеннән өземтә һәм йортка техник паспорт җирле үзидарә органы тарафыннан дәүләт органнарыннан, башка җирле үзидарә органнарыннан яисә аларга буйсынган оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып алына торган документларга кертелгәннәр һәм шунлыктан мөрәҗәгать итүчедән таләп ителә алмыйлар.

Шуңа бәйле рәвештә гражданин И.А. Макаров социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ буларак исәпкә куюдан йорт кенәгәсеннән өземтә бирелмәү нигезендә баш тарту законсыз булып тора һәм хокук нормалары белән бәйләнмәгән дип саный.

Моннан тыш, аның фикеренчә, аның тарафыннан дәгъва белдерелә торган Административ регламентның хокукый нигезләмәләре белән йорт кенәгәсен һәм шәхси торак йортка хокуклар турындагы документны мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә тиешле документларга кертү шулай ук законсыз һәм җирле үзидарә органнары карарларының һәм гамәлләренең законлы характеры турында конституциячел норма белән килешмәүче булып тора.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин И.А. Макаров Татарстан Республикасы Конституция судыннан «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасын, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче

абзацлары белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктларының аерым нигезләмәләрен Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 30, 54 (беренче өлеш), 55 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый, алар нигезендә Татарстан Республикасы — сәясәте кешегә лаеклы тормыш һәм иркле үсеш тәэмин итүче шартлар булдыруга юнәлтелгән социаль дәүләт; дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар, учреждениеләр, урындагы затлар һәм гражданнар Татарстан Республикасы Конституциясен һәм законнарын үтәргә бурычлы; закон һәм суд каршында һәркем тигез; дәүләт кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең тигезлеген чыгышына, социаль һәм мөлкәти хәленә, яшәү урынына һәм башка шартларга бәйсез рәвештә гарантияли; расачыл, милли һәм башка билгеләр буенча гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен чикләүнең яки аларга өстенлекләрен билгеләүнең теләсә кайсы рәвеше тыела; гражданнар шәхси, сәяси, социаль-икътисадый һәм мәдәни хокукларның һәм ирекләрнең бөтен тулылыгына ия; һәркемгә авырган, гарипләнгән һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә; һәркем торакка хокуклы, беркем дә торагыннан нигезсез мәхрүм ителә алмый; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар; Татарстан Республикасында кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгаручы яисә киметүче законнар чыгарылмаска тиеш.

1.1. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы икенче өлеше нигезендә, конституциячеллеге дәгъваланучы акт юкка чыгарылган булса яисә эшне карый башлаганчы йә аны карау чорында үз көчен югалткан булса, Татарстан Республикасы Конституция суды башлаган эш туктатылырга мөмкин, моңа бу актның гамәлдә булуы аркасында гражданнарның конституциячел хокуклары

һәм ирекләре бозылган очраклар керми.

Суд утырышында эшне карый башлаганчы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2019 елның 30 декабрендәге 4714 номерлы карары белән дәгъва белдерелә торган карарга үзгәрешләр кертелгән, алар нигезендә Административ регламентка 1 нче кушымта яңа редакциядә бәян ителгән. Кертелгән үзгәрешләр эчтәлегеннән күренгәнчә, мөрәҗәгать итүче шикаять белдерә торган Административ регламентка 1 нче кушымтадагы 1 пунктының дүртенче абзацындагы шәхси торак йортка хокуклар турындагы документ (хокукны дәүләт теркәве турында таныклык яки шәхси торак йортның техник (кадастр) паспорты, яки Ростехинвентаризациянең — Федераль техник инвентаризацияләү бюросының Татарстан Республикасы филиалыннан хокук ияләре турында белешмә) бирү бурычына кагылышлы нигезләмә төшереп калдырылган. Димәк, әлеге эш буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы дүртенче абзацы белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктлары нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерү өлешендә эш туктатылырга тиеш.

Шуның белән бергә, кертелгән үзгәрешләр эчтәлегеннән шулай ук күренгәнчә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан йорт кенәгәсен бирү бурычларына кагылышлы нигезләмә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Башкарма комитетның 2019 елның 30 декабрендәге 4714 номерлы карары редакциясендә) расланган Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымтаның беренче өлешендәге 3 пунктында фактта сакланып калган һәм чагылыш тапкан. Күрсәтелгән нормалар аның торакка конституциячел хокукын бозуга хокукый

нигез булып торган дип санаган мөрәҗәгать итүче позициясен исәпкә алып, Административ регламентның карала торган нормаларына үзгәрешләр кертү алар белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчегә йорт кенәгәсен бирү бурычын йөкләгән дәрәҗәдә дәгъва белдерелә торган нигезләмәләрнең конституциячеллеген тикшерүгә каршы килә алмый.

1.2. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 68 статьясындагы икенче һәм өченче өлешләре нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды, карала торган актның мәгънәсен сүзгә-сүз, рәсми рәвештә һәм башкача шәрехләп яки хокук куллану гамәлиятендәге мәгънәсен дә бәяләп, шулай ук норматив хокукый актлар системасындагы урынын исәпкә алып, эш буенча карар кабул итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән предмет буенча һәм мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән актның конституциячеллеге шик тудыручы өлешенә карата гына карар кабул итә һәм карар кабул иткәндә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән сәбәпләргә һәм дәлилләргә бәйле булмый.

Шулай итеп, әлеге эш буенча түбәндәгеләр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметы булып торалар:

— «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасы, аның нигезендә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пунктында «торак урыннарга мохтаҗ дип» сүзләре «билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип» сүзләренә алмаштырылган;

— Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре

муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче абзацы белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктлары нигезләмәләре, алар йорт кенәгәсеннән белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчегә йорт кенәгәсен бирү бурычын йөкләгән дәрәҗәдә.

2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының хокукый нигезләмәләре социаль яклау һәм торак законнары өлкәсенә кагылалар. Россия Федерациясе Конституциясенең 72 статьясы (1 өлешнең «ж» һәм «к» пунктлары) нигезендә, социаль тәэминатны да кертеп, социаль яклау, шулай ук торак законнары Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында. Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм Россия Федерациясе субъектларының шулар нигезендә кабул ителә торган законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла; Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары федераль законнарга каршы килә алмый (Россия Федерациясе Конституциясенең 76 статьясы, икенче һәм бишенче өлешләр).

«Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль законның 26.3 статьясы нигезендә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнарының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча әлеге органнар тарафыннан Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары хисабына (федераль бюджеттан бирелгән субвенцияләрдән тыш) мөстәкыйль гамәлгә ашырыла торган вәкаләтләренә гражданнарның аерым категорияләренә, шул исәптән инвалидларга, социаль ярдәм һәм социаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен хәл итү керә (2 пунктның 24 пунктчасы); әлеге мәсьәләләр

буенча федераль законнарда күрсәтелгән хокукны билгели торган нигезләмәләр булу-булмауга бәйсез рәвештә Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары законнар, башка норматив хокукый актлар кабул итәргә хокуклы (3.1 пункт).

Аталган Федераль законның 26.3-1 статьясындагы өченче өлеше нигезендә Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчалары исәбеннән (федераль бюджеттан максатчан чыгымнарны гамәлгә ашыру өчен Россия Федерациясе субъекты бюджетына тапшырыла торган финанс чараларыннан тыш) гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль ярдәм күрсәтүнең һәм социаль булышуның өстәмә чараларын шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән билгеләнгән мохтаҗлык критерийларыннан чыгып билгеләргә хокуклы, бу федераль законнарда әлеге хокукны билгели торган нигезләмәләрнең булу-булмавына бәйле түгел.

Шулай итеп, 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын кабул итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы үзенә федераль законнар нигезендә карый торган һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 54 (икенче өлеш) һәм 75 (2 пункт) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтне дөрес гамәлгә ашырган.

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 3 статьясы нигезендә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне норматив хокукый җайга салу әлеге Федераль закон, башка федераль законнар белән, алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектлары законнары һәм башка норматив хокукый актлары, муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Күрсәтелгән Федераль законның 12 (1 өлеш) һәм 13 (15 өлеш) статьялары белән үзара бәйләнештә 6 статьясы нигезендә муниципаль

хезмәтләр күрсәтүче органнар административ регламентлар нигезендә муниципаль хезмәтләр күрсәтергә тиеш; муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе җирле администрация тарафыннан билгеләнә.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенең 1.8 пункты нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлкәсендә административ регламентлар билгеләнгән тәртиптә Казан шәһәре Башкарма комитетының хокукый акты белән расланалар.

Шулай итеп, Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслап, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты үзенә федераль законнар нигезендә бирелгән, шулай ук Татарстан Республикасы Конституциясенең 116 (беренче өлеш) һәм 118 (беренче өлеш) статьяларының үзара бәйле нигезләмәләренә таянган вәкаләтләрне дөрес гамәлгә ашырган.

3. Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасын социаль дәүләт дип игълан итеп (13 статья), һәркемгә, шул исәптән авырган, гарипләнгән очракта һәм законда билгеләнгән башка очракларда социаль тәэминат гарантияләнә (54 статья, беренче өлеш); һәркем торакка хокуклы; дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары торак төзелешен хуплыйлар, торакка хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыралар (55 статья) дип билгели. Мәгънәсе буенча шундый ук гарантияләр Россия Федерациясе Конституциясендә, шул исәптән аның 7, 39 (1 өлеш), 40 (1 һәм 2 өлешләр) статьяларында билгеләнгән.

Шул ук вакытта, Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләп үткәнчә, Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә, Россия, сәясәте кеше өчен лаеклы тормыш һәм иркле үсеш тәэмин итәрлек шартлар тудыруга юнәлдерелгән социаль дәүләт буларак (7 статья, 1 өлеш), һәркемнең торакка

хокукын гамәлгә ашыруны гарантияли (40 статья, 1 өлеш), ул, лаеклы тормыш дәрәҗәсенә хокук элементы буларак, халыкара җәмәгатьчелек тарафыннан танылган (Кеше хокуклары гомуми декларациясенең 25 статьясы һәм Икътисади, социаль һәм мәдәни хокуклар турында халыкара пактның 11 статьясы). Шуннан чыгып, Россия Федерациясе Конституциясе, һәркемнең торакка хокукын игълан итеп, әлеге хокукны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру буенча дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының үзара бәйләнешле булу бурычын беркетә (40 статья, 2 өлеш), бер үк вакытта аны гамәлгә ашыру гарантиясе булып тора (2016 елның 12 апрелендәге 10-П номерлы Карар).

3.1. Бюджетларның мөстәкыйльлеге принцибы нигезендә (Россия Федерациясе Бюджет кодексының 31 статьясы), Россия Федерациясе Конституция Суды билгеләгәнчә, Россия Федерациясе субъектының бюджеты акчаларын тоту формалары һәм юнәлешләре (финанс белән тәэмин ителеше башка дәрәҗәләрдәге бюджетлардан субсидияләр һәм субвенцияләр исәбеннән гамәлгә ашырыла торган чыгымнардан тыш) Россия Федерациясе субъектлары тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә, ләкин шул ук вакытта алар хокуклы гына түгел, шулай ук үз бюджетларының баланслылыгын һәм бюджет акчаларын куллануның нәтиҗәлелеген мөстәкыйль тәэмин итәргә дә тиешләр (2018 елның 27 мартындагы 13-П номерлы Карар).

«Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясында билгеләнгән хокукый җайга салу максатчан характерга ия, аның билгеләнеше тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла торган аерым категорияләрдәге гражданнарның матди иминлеген тәэмин итү булып тора һәм гражданнарның аерым категорияләренә өстәмә социаль ярдәм чарасыннан гыйбарәт, аны билгеләү Татарстан Республикасының бурычы түгел, ә хокукы булып тора дип Татарстан Республикасы Конституция суды берничә тапкыр күрсәткән иде инде. Бу исә аны бирү нигезләре һәм шартлары, социаль-икътисадый үсешнең әлеге этабында булган финанс һәм башка матди

мөмкинлекләрне исәпкә алып, республика тарафыннан мөстәкыйль билгеләнә дигәнне аңлата (2016 елның 8 июлендәге 12-О номерлы, 2017 елның 12 июлендәге 32-О номерлы һәм башка билгеләмәләр).

Торак шартларын яхшыртуга торак субсидиясен (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) (алга таба шулай ук — торак субсидиясе) бирү рәвешендә өстәмә социаль ярдәм чарасы «"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июлендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 3 пункты белән кертелгән. Башта Татарстан Республикасы закон чыгаручысы Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче инвалидлар һәм әлеге исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче инвалид балалары булган (алга таба шулай ук — инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр), торак урыннарына мохтаҗлар дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан гаиләләр өчен торак субсидиясен бирүне күздә тоткан.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан шикаять белдерелә торган 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, аны алу хокукына билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗлар дип танылган инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр ия булуын күздә тотып, торак субсидиясе бирү шартларын үзгәрткән. Россия Федерациясе Торак кодексының социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелү шартларын регламентлый торган 91.3 статьясының 1 өлеше нигезләмәләре белән үзара бәйләнештә, бу торак урыннарына мохтаҗлар дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр саныннан аз керемлеләр дип танылган яки

танылырга нигезе булганнар, шулай ук аларның һәм алар белән бергә даими яшәүче гаилә әгъзалары керемenең һәм аларның салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә билгеләнә торган максималь күләмнән артып китүчеләр төшереп калдырылганны аңлата.

Торак урыннарына мохтаҗлар дип танылган яисә танылырга нигезләре булган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә баскан торак урыннарына мохтаҗ инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр өчен хокукый җайга салуны үзгәрткәндә, Татарстан Республикасы закон чыгаручысы, Татарстан Республикасы бюджетының булган мөмкинлекләреннән чыгып, күрсәтелгән категориядәге затлар өчен федераль закон чыгаручы тарафыннан торак шартларын яхшырту механизмы инде каралган булуын кулланган.

Россия Федерациясе Торак кодексының 14 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты, 49 статьясындагы 2 өлеше һәм 57 статьясындагы 2 өлеше 3 пунктының үзара бәйләнешле нигезләмәләре эчтәлегеннән күренгәнчә, әлеге Кодексның 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче гражданнар, аларны аз керемлеләр дип таныган һәм торак законнарында каралган тәртиптә алар тарафыннан торак урынына мохтаҗлыгы расланган очракта, социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак урыннары чираттан тыш бирелү хокукына ия.

Россия Федерациясе Конституция Суды 2019 елның 10 декабрендәге 39-П номерлы Карарында, социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә һәм торак урынына объектив мохтаҗлыкны раслауга карата торак законнарының гомуми таләпләрен үтәү шарты белән (әлеге Кодексның 49 статьясындагы 2 өлеше һәм 52 статьясындагы 1 өлеше), федераль закон чыгаручы гражданнарның аерым категорияләре өчен социаль наем шартнамәләре буенча чираттан тыш, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче

гражданнар өчен торак урыннары бирү мөмкинлеген билгеләгән (әлеге Кодексның 57 статьясындагы 2 өлешенең 3 пункты), дип күрсәтеп киткән.

Бәян ителгәннәрне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Конституция суды, аз керемлеләр дип танылган инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр аларга муниципаль торак фондыннан торак урыны бирү юлы белән торак шартларын яхшыртуга хокуклы, ә аз керемлеләр дип танылмаган шундый ук затлар категориясендәге гражданнар мондый хокукка ия түгел, дәгъва белдерелә торган хокукый җайга салуны кертү хроник авыруларның авыр формалары белән интегүче һәм билгеләнгән тәртиптә торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ дип танылган иң күп сандагы инвалидларга дәүләт ярдәме күрсәтүне, бюджет акчалары хисабына үзенең хокукый табигате буенча охшаш социаль ярдәм чараларын берничә тапкыр алуны булдырмауны максат итеп куя һәм үзеннән-үзе конституциячел әһәмиятле максатны — аңа аеруча мохтаҗ гражданнарның торакка хокукын тәэмин итүне күздә тота дигән нәтиҗәгә килә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының карала торган җайга салуны үзгәртүдә мондый алымы Россия Федерациясе Конституция Судының хокукый позицияләренә җавап бирә, ул берничә тапкыр күрсәткәнчә, гаделлек, тигезлек һәм ярашканлык конституциячел принципларыннан закон чыгаручыга юнәлтелгән бер үк категориягә караган затларның хокукый хәлендә объектив һәм акылга ярашлы аклануга ия булмаган аерымлыклар кертүне тыю (бер үк яисә охшаш вәзгыятьләрдә торучы затлар белән төрлечә эш итүне тыю) килеп чыга; хокукый җайга салуның теге яки бу өлкәсендә гражданнарның хокукларындагы аермаларга китерә торган теләсә нинди дифференциация Россия Федерациясе Конституциясе, шул исәптән аның 17 (3 өлеш), 19 (1 һәм 2 өлешләр) һәм 55 (3 өлеш) статьялары таләпләренә җавап бирергә тиеш, әгәр аермалар бары тик объектив акланган, нигезләнгән һәм конституциячел әһәмиятле максатларга туры килсә генә рөхсәт ителә, ә әлеге максатларга ирешү өчен файдаланыла торган хокукый чаралар шуларга тиң (2001 елның 24 маендагы 8-П номерлы, 2007 елның 5 апрелендәге

5-П номерлы, 2010 елның 3 февралендәге 3-П номерлы, 2012 елның 27 февралендәге 3-П номерлы, 2019 елның 22 мартындагы 15-П номерлы һәм башка карарлар).

Шуның белән бергә, Татарстан Республикасы Конституция суды мондый дифференциациянең аз керемлеләр дип танылган, шулай ук андый дип танылмаган инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр мәнфәгатьләре балансын үтәгәндә генә акланырга мөмкин булуына игътибар итә, бу исә дәүләт хакимияте органнарыннан һәм җирле үзидарә органнарыннан натуралата торак урынын чиратсыз бирү яки торак субсидиясен түләү буенча закон нигезендә билгеләнгән бурычларын реаль үтәүне, димәк, торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ гражданнарның санын исәпкә алып, тиешле бюджет планлаштыруын таләп итә.

Шулай итеп, «"Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасы, аның нигезендә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пунктында «торак урыннарга мохтаҗ дип» сүзләре «билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип» сүзләренә алмаштырылган, Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә.

3.2. Дәгъва белдерелә торган закон нормасын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танып, Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтәргә кирәк дип саный. Россия Федерациясе Конституция Суды күрсәткәнчә, Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысына гражданнарның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтүнең өстәмә чараларын билгеләү һәм юкка чыгару вәкаләте бирү ул чикләнмәгән ирекле эш итә һәм элек үз өстенә алган гавами-хокукый

йөкләмәләрдән баш тарта ала дигәнне аңлатмый. Киресенчә, аларны саклауга бөтен көчен куеп, ул конституцион әһәмиятле кыйммәтләр, гавами һәм шәхси мәнфәгатьләр балансын табарга, әгәр дә, Россия Федерациясе субъекты бюджеты торышын исәпкә алып, бу объектив мөмкин түгел икән, һәрхәлдә, законнар белән җайга салуга нигезләнеп көткән һәм тиешле социаль ярдәм чараларын алуга исәп тоткан затлар өчен тискәре нәтиҗәләрне мөмкин кадәр йомшартырга тиеш. Башкача булуы социаль дәүләт нигезенә каршы килү генә түгел, Россия Федерациясе Конституциясенең законнарның мәгънәсен, эчтәлеген һәм кулланылышын билгеләүче 2 һәм 18 статьяларыннан килеп чыга торган һәм гавами хакимият органнарына мөрәҗәгать ителгән кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклауны тәэмин итү таләбе белән дә аерылыр иде (2018 елның 27 мартындагы 13-П номерлы Карар).

Шулай итеп, социаль ярдәмнең теге яки бу өстәмә чарасын юкка чыгарып, Татарстан Республикасы закон чыгаручысына алга таба социаль ярдәм чараларын, аерым алганда, торак субсидиясен бирүнең элек билгеләнгән шартларын үзгәрткәндә, гражданнарның законга һәм дәүләт гамәлләренә ышанычын хуплау принцибын сакларга мөмкинлек бирә торган компенсация механизмын күздә тотарга кирәк, ул хокукый җайга салуның нигезле тотрыклылыгын саклауны һәм гамәлдәге нормалар системасына законсыз үзгәрешләр кертүгә юл куелмауны, шулай ук гражданнарга кирәк булган очракта, аерым алганда, вакытлыча җайга салу юлы белән, ниндидер бер нигезле күчеш чоры дәвамында кертелә торган үзгәрешләргә җайлашу өчен мөмкинлек бирүне күздә тота.

Моннан тыш, «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» законның, аның башлангыч редакциясендә, 8.2 статьясы гамәлдә булган чорда, Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә, шул исәптән аз керемлеләр дип танылган гаиләләргә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан, бу хакта әлеге Татарстан Республикасы Законында турыдан-туры күрсәтелүгә карамастан, әлеге социаль ярдәм

чарасын бирүне күздә торак субсидиясен исәпләү тәртибе расланмаган булган. Күрсәтелгән тәртип «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карары белән, ягъни мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган закон үзгәрешләре кертелгәннән соң ук расланган. Шуның нәтиҗәсендә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» (башлангыч редакциясендә) Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булу чорында аның 8.2 статьясы нигезендә торак субсидиясе хокукына ия булган инвалидлар һәм инвалид балалары булган гаиләләр мондый хокуктан, аны гамәлгә ашыру тәртибе булмау сәбәпле, файдалана алмаганнар. Бу закон чыгаручы тарафыннан билгеләнгән хокук асылда иллюзор характерда булган дигәнне аңлата. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының игътибарын шуңа юнәлтергә кирәк дип саный: закон нормасын юридик тәэмин итү механизмы булмау гавами хакимият органнарының ирекле каравына китерергә мөмкин, ә бу хокукый дәүләтнең конституциячел принциплары белән туры килми һәм тиешле хокукый җайга салуны гамәлгә ашырганда киләчәктә һич тә ярамый.

4. Йорт кенәгәсеннән өземтә бирү буенча дәүләт (муниципаль) хезмәте Россия Федерациясе субъектлары башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан электрон рәвештә беренче чиратта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләрнең, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары учреждениеләре һәм оешмалары һәм муниципаль учреждениеләр һәм оешмалар тарафыннан электрон рәвештә күрсәтелә торган хезмәтләрнең (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 17 декабрендәге 1993-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган) һәм дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр реестрына кертелергә тиешле һәм электрон формада күрсәтелә торган, аларда дәүләт йөкләмәсе (заказы) яки муниципаль йөкләмә

(заказ) урнаштырылган дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр һәм башка оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең (Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 25 апрелендәге 729-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган) җыелма исемлегенә кертелгән.

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон, ведомствоара, шул исәптән электрон, дәүләт хакимияте органнары һәм (яки) җирле үзидарә органнары арасында үзара бәйләнешне кертү һәм үстерү зарурлыгыннан чыгып, муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары һәм муниципаль органнар яки мондый хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы аларга караган оешмалар карамагында булган документларны таләп итәргә хокуклы булмавын күздә тоткан, мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән документларны һәм мәгълүматны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы (7 статьяның 1 өлешендәге 2 пункты). Югарыда күрсәтелгән Федераль законда мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөстәкыйль бирелә торган документлар исемлеген билгеләп, федераль закон чыгаручы Россия Федерациясе субъекты законы яисә Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы норматив хокукый акты яисә муниципаль хокукый акт нигезендә күрсәтелгән исемлектән документлар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын кулланып алынырга мөмкинлеген (7 статьяның 6 һәм 6.1 өлешләре) күздә тоткан.

Шул ук вакытта закон яисә башка норматив хокукый актлар нигезендә мөрәҗәгать итүче мөстәкыйль тапшырырга тиешле мәгълүматка һәм документларга, һәм, алар ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алынырга тиешле булганлыктан, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы документларга бүлеп муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле булган документларның тулы исемлеге муниципаль хезмәт күрсәтү стандартында билгеләнә, ул, үз чиратында, административ регламент структурасына керә («Дәүләт хезмәтләре һәм

муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законның 12 статьясындагы 2 өлешенең 2 пункты һәм 14 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты).

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән расланган (башлангыч редакциясендә) Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 1.9 пунктындагы өченче абзацы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган белешмә (өземтә) — шәхси торак йортларда яшәүчеләргә бирелә торган гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтә, йорт кенәгәсеннән өземтә, вафат булучының яшәгән урыныннан вафат булган көненә белешмә, алдагы яшәү урыныннан белешмә.

Административ регламентның шикаять белдерелә торган нигезләмәләре буенча йорт кенәгәсеннән өземтә бирү өчен мөрәҗәгать итүче шул исәптән йорт кенәгәсен дә бирергә тиеш.

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының «Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәү һәм теркәүдән төшерү кагыйдәләрен куллану турындагы инструкцияне раслау хакында» 1995 елның 23 октябрендәге 393 номерлы Боерыгы эчтәлегеннән күренгәнчә (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының 2007 елның 16 ноябрендәге 1004 номерлы Боерыгы басылуга бәйле рәвештә үз көчен югалткан), йорт (фатирлар буенча) кенәгәләре гражданнарның милек хокукында булган торак урыннарында гражданнар теркәлгәндә рәсмиләштерелә, алар йорт (фатир) хуҗаларында саклана; йорт (фатирлар буенча) кенәгәләре — һәр йортка, ә йорт (фатир) милектәшләренең үтенече буенча йортның (фатирның) һәр өлешенә алып барылалар. Россия Федерациясе Федераль миграция хезмәтенең «Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәү исәбенә алу буенча Федераль миграция хезмәте тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын

раслау турында» 2007 елның 20 сентябрендәге 208 номерлы (Россия Федерациясе Федераль миграция хезмәтенең 2012 елның 11 сентябрендәге 288 номерлы Боерыгын бастырып чыгаруга бәйле рәвештә үз көчен югалткан) Боерыгы белән гражданнарны физик яки юридик затларның милек хокукында булган шәхси торак фондының торак урыннарына теркәгәндә, торак урыны милекчесенең (милекчеләренең) торак фонды белән идарә итүче оешма белән әлеге эшне алып бару өчен килешүе булмаган очракта, йорт (фатир) хуҗалары тарафыннан 11 номерлы форма буенча йорт (фатирлар буенча) кенәгәләрен рәсмиләштерү һәм саклау рөхсәт ителә (59 пункт) дип каралган иде. Алга таба торак урыннар милекчеләре тарафыннан йорт кенәгәсен алып бару буенча шундый ук бурыч Россия Федерациясе Федераль миграция хезмәтенең «Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәү исәбенә алу буенча Федераль миграция хезмәте тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 11 сентябрендәге 288 номерлы Боерыгы белән каралган иде (Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының 2017 елның 31 декабрендәге 984 номерлы Боерыгын чыгаруга бәйле рәвештә үз көчен югалткан). Хәзерге вакытта гамәлдә булган законнар белән йорт кенәгәләрен электрон рәвештә дә, кәгазьдә дә алып бару, шулай ук гражданнарның үзләрендә булган йорт кенәгәләрен Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәү исәбенә алучы органнарга яисә башка гавами хакимият органнарына һәм оешмаларга тапшыру буенча да бурычлары каралмаган.

Аталган хокукый нигезләмәләрдән чыгып, йорт кенәгәләрен алып бару бурычы шәхси торак йортларның милекчеләренә йөкләнгән. Димәк, гражданга муниципаль хезмәт күрсәткәндә аңа йорт кенәгәсеннән өземтә бирү өчен йорт кенәгәсен бирү турындагы таләп мөрәҗәгать итүче индивидуаль торак йортның милекчесе булуына, йорт кенәгәсе аның карамагында булуына һәм җирле администрациянең аны ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алу мөмкинлеге булмауга бәйле объектив хәлләргә нигезләнгән.

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар буларак исәпкә кую өчен гражданнар тарафыннан йорт кенәгәсеннән өземтәләр бирү буенча таләпләр булмавы турында мөрәҗәгать итүченең дәлилләренә карата Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрне билгеләп үтә.

Гражданнарны социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннары бирүгә мохтаҗлар буларак исәпкә кую өчен йорт кенәгәсеннән өземтә бирергә кирәклеге, шулай ук мондый өземтә бирмәү нәтиҗәләре — тиешле исәпкә куелудан баш тарту турында таләпне билгели торган хокукый нигезләмәләр дәгъва белдерелә торган Административ регламентта каралмаган. Әлеге таләп Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 13 ноябрендәге 5805 номерлы карары белән расланган Казан шәһәрендә социаль кулланылыштагы торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре нигезендә торак урыннар алуга мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтү турында Административ регламентында билгеләнгән, аның конституциячеллеге гражданин И.А. Макаров тарафыннан дәгъваланмый, шуңа күрә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан конкрет нормоконтроль тәртибендә карала торган әлеге эш кысаларында бәяләнә алмый.

Шулай итеп, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче абзацы белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктларының дәгъва

белдерелә торган нигезләмәләре, алар йорт кенәгәсеннән белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчегә йорт кенәгәсен бирү бурычын йөкләгән дәрәҗәдә кеше һәм гражданның, шул исәптән гражданин И.А. Макаровның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен юкка чыгара, чикли яисә башкача боза торган буларак карала алмый һәм шуңа күрә Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 30, 54 (беренче өлеш), 55 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына каршы килми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 6 статьясына, 46 статьясындагы икенче өлешенә, 66 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 67 статьясындагы беренче, икенче һәм алтынчы өлешләренә, 68, 69, 71, 73 статьяларына һәм 104 статьясындагы беренче өлешенең 1 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**карар чыгарды:**

1. «“Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 5 декабрендәге 100-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясының 5 пунктындагы «а» пунктчасын Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга, аның нигезендә «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясындагы 1 пунктында «торак урыннарга мохтаҗ дип» сүзләре «билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип» сүзләренә алмаштырылган.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ

регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче абзацы белән үзара бәйләнештә, Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктлары нигезләмәләрен, алар йорт кенәгәсеннән белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүчегә йорт кенәгәсен бирү бурычын йөкләгән дәрәҗәдә Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килә дип танырга.

3. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2013 елның 21 ноябрендәге 10100 номерлы карары белән (Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2016 елның 28 октябрендәге 4439 номерлы карары редакциясендә) расланган әлеге Административ регламентка 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы дүртенче абзацы белән үзара бәйләнештә Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2.5 һәм 2.8 пунктлары нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерүгә кагылышлы өлешендә әлеге эшне карауны туктатырга.

4. Әлеге Карар катгый, шикаятькә дучар ителә алмый, игълан ителү белән үз көченә керә, турыдан-туры гамәлдә була һәм башка органнар һәм вазыйфаи затлар тарафыннан раслануны таләп итми.

5. Әлеге Карар «Ватаным Татарстан», «Республика Татарстан» газеталарында һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) кичекмәстән басылып чыгарга тиеш. Карар шулай ук «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

**№ 88-П**

**Татарстан Республикасы**
**Конституция суды**